ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт,Печищи авылы,
422592

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа-Болгар авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында

№2 12.04.2024

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында" Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы гражданнары җыенының 14.10.2023 ел, №1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 50 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 32 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- гражданнар җыенының 32 катнашучысы «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;
- «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде
- 0 катнашучы тавыш бирүдән тыелып калды

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Яңа-Болгар авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.
2. "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында" Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы гражданнары җыенының 14.10.2023 ел, №1 карарына үзгәрешләр кертү турында карарны танырга: - «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылында Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылында

теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне (су алу җайланмасын төзекләндерү) тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

3. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылы гражданнары җыенының нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш. Р. Азизов